# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

Әлеге Закон Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең статусын, компетенциясен, үз вазыйфасына сайлану, аның вәкаләтләре туктатылу һәм аны вазыйфасыннан азат итү тәртибен, шулай ук аның эшчәнлеген тәэмин итү нигезләрен билгели.

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил**

1. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) вазыйфасы БМОның Бала хокуклары турындагы конвенциясе, Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен тәэмин итү, әлеге хокукларны һәм мәнфәгатьләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан тану һәм үтәү максатларында гамәлгә куела.
2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы булып тора.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, кайсы да булса Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга бәйсез һәм алар алдында хисап тотмый.

4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклауның гамәлдәге чараларын тулыландыра, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны, баланың бозылган хокукларын торгызуны тәэмин итүче Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар компетенцияләрен юкка чыгармый һәм яңадан карауга китерми.

## 2 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең хокукый нигезләре

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз эшчәнлегендә халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә, БМОның Бала хокуклары турындагы конвенциясенә, Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, әлеге Законга һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына таяна.

## 3 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бурычлары

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен тәэмин итү;

2) баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуга ярдәм итү;

3) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау механизмын камилләштерүгә ярдәм итү;

4) Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү эшләре торышын анализлау;

5) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны камилләштерүгә ярдәм итү;

6) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарының үзара эшчәнлегенә ярдәм итү;

7) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча халыкны хокукый агарту;

8) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендә региональ һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерү.

2. Тормыш хәле авыр булган балаларның, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә өстенлекле юнәлеш булып тора.

### 4 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге принциплары

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге законлылык, бәйсезлек, гаделлек, җаваплылык, гуманлык, ачыклык, объективлык һәм һәркем өчен файдаланырлык булу принципларына нигезләнә.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе субъектларындагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар, аларның вазыйфаи затлары, иҗтимагый берләшмәләр белән үзара эшчәнлекне һәм хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүчеләрнең һәм башка затларның бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау эшчәнлегенә бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган шәхси тормышлары турындагы белешмәләрне фаш итәргә хокуксыз.

## 2 бүлек. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына сайлап кую, аның вәкаләтләрен туктату һәм аны вазыйфасыннан азат итү тәртибе

### 5 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатка карата куела торган таләпләр

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына 35 яшьтән дә яшь булмаган, юридик яисә педагогик югары һөнәри белемле, үзенә тап төшергән гамәлләр кылмаган, балалар проблемаларын белүче йә балалар белән эш тәҗрибәсенә, йә бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә эш тәҗрибәсенә ия Россия Федерациясе гражданы булып торучы зат сайланып куела.

### 6 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына сайлап кую

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфага Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлап куела.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тәкъдим итә.

**7 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үз вазыйфасына керешүе**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге эчтәлекле антны әйткән мизгелдән үз вазыйфасына керешкән булып санала:

"Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен якларга, үз вазыйфаларымны Берләшкән Милләтләр Оешмасының Бала хокуклары турындагы конвенциясенә, Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, гаделлеккә таянып һәм намус кушканча башкарырга сүз бирәм".

2. Ант итү, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз вазыйфасына сайланып куелганнан соң, турыдан-туры Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында башкарыла.

**8 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре срогы**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз вазыйфасына биш ел срокка сайланып куела.

2. Бер үк зат Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына тоташтан ике сроктан артыкка сайланып куела алмый.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре Бала хокуклары буенча яңа вәкаләтле вәкил сайланган көннән туктатыла.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре срогы чыгу яисә аны тарату Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен туктатуга китерми.

**9 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үз вәкаләтләрен башкаруга бәйле чикләүләр**

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.

**10 статья. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне үз вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз вазыйфасыннан вакытыннан алда федераль законнарда һәм "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда һәм тәртиптә азат ителә.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне үз вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары санынннан күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне үз вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан куела.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителгән очракта, Бала хокуклары буенча яңа вәкаләтле вәкил Бала хокуклары буенча элекке вәкаләтле вәкил үз вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителгән көннән алып ике ай эчендә әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайланырга тиеш.

## 3 бүлек. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил компетенциясе**

### 11 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре**

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз бурычларын үтәү максатларында:

1) Татарстан Республикасында БМОның Бала хокуклары турындагы конвенциясен, халыкара хокукның башка нормаларын һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрен, Россия Федерациясе Конституциясен, Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау һәм үтәү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын үтәү торышын өйрәнә;

2) гражданнарны кабул итүне гамәлгә ашыра, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуга кагылышлы мөрәҗәгатьләрне, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарының, вазыйфаи затларның, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмаларның бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен боза торган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата гражданнар шикаятьләрен карый;

3) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар, аларның вазыйфаи затлары эшчәнлеген, шулай ук бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу фактлары турындагы хәбәрләрне мөстәкыйль рәвештә яисә компетентлы дәүләт органнары һәм вазыйфаи затлар белән берлектә тикшерә;

4) балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен күпләп яисә тупас бозулар турында мәгълүматлар алганда йә аеруча иҗтимагый әһәмияткә ия булган очракларда үз инициативасы белән үз компетенциясе чикләрендә тиешле чаралар күрә;

5) балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу фактларын тикшерү буенча парламент комиссиясе төзү һәм парламент тыңлаулары үткәрү турындагы тәкъдимнәр белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать итә, шулай ук турыдан-туры яисә үз вәкиле аша күрсәтелгән комиссия эшендә һәм үткәрелә торган тыңлауларда катнаша;

6) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) ул бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозыла дип таныган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте

органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына, аларның вазыйфаи затларына, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмаларга баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызу һәм алга таба мондый хокук бозуларны булдырмау буенча ихтимал һәм кирәкле чараларга кагылышлы тәкъдимнәрне үз эченә ала торган бәяләмәсен юллый;

7) балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре федераль дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан органнары тарафыннан бозылган очракта, бу органнарга күрсәтелгән хокукларны һәм мәнфәгатьләрне торгызу буенча ихтимал һәм кирәкле чараларга кагылышлы тәкъдимнәр җибәрә, шулай ук Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә хокук саклау органнарына һәм башка компетентлы органнарга мөрәҗәгать итә;

8) бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актлар эшләүдә катнаша;

9) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертә;

10) Татарстан Республикасы Президенты каравына бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү һәм яклау мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертә;

11) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарыннан алына торган материаллардагы, шулай ук күрсәтелгән мәсьәләләр буенча гражданнар, оешмалар мөрәҗәгатьләрендәге, массакүләм мәгълүмат чараларындагы хәбәрләрдәге мәгълүматны җыюны, өйрәнүне һәм анализлауны гамәлгә ашыра;

12) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозулар чагыла торган вазыйфаи затларга карата дисциплинар, административ эш йә җинаять эше кузгату турында үтенечнамә белән дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына мөрәҗәгать итә;

13) Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу фактлары турында хокук саклау органнарына хәбәр итә;

14) балаларның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә тискәре йогынты ясый торган хәлләрне билгеләү максатында басма, аудио- һәм видеопродукциягә мониторинг алып бара;

15) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итә;

16) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә судта яклауны гамәлгә ашыра;

17) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча балаларга, шулай ук аларның законлы вәкилләренә консультатив ярдәм күрсәтә;

18) үз компетенциясе чикләрендә, бер яктан, балалар, аларның законлы вәкилләре һәм, икенче яктан, гамәлләренә карата шикаять бирелә торган дәүләт

хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары, оешмалар арасындагы бәхәсләрне җайга салу буенча чаралар күрә;

19) бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре, аларны яклау рәвешләре һәм ысуллары мәсьәләләре буенча хокукый агартуны, БМОның Бала хокуклары турындагы конвенциясе, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, бала хокуклары мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен пропагандалауны гамәлгә ашыра;

20) гамәлдәге законнарда каралган башка вәкаләтләрне башкара.

## 12 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге гарантияләре**

1. Үз бурычларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары тарафыннан кичекмәстән кабул ителергә;

2) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарыннан, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалардан, аларның вазыйфаи затларыннан билгеләнгән тәртиптә кирәкле белешмәләр, документлар, материаллар, аңлатмалар һәм башка мәгълүмат сорарга һәм алырга;

3) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмаларга, таныклык күрсәтеп, каршылыксыз керергә;

4) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы территориясендәге хокук саклау органнарына һәм ирексезләп тоту урыннарына таныклык күрсәтеп керергә, шулай ук федераль законнар нигезендә аларның җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителергә;

5) белем бирү учреждениеләренә, мәгариф идарәсе органнарының ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениеләренә, балаларга медицина ярдәме күрсәтә торган сәламәтлек саклау учреждениеләренә, авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен социаль приютларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга ярдәм итү үзәкләренә, эчке эшләр органнарының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәкләренә, башка учреждениеләргә, таныклык күрсәтеп, каршылыксыз керергә һәм аларда балаларны тоту шартларын тикшерергә;

6) бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары буенча мөстәкыйль рәвештә яисә компетентлы дәүләт органнары, вазыйфаи затлар белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар эшчәнлегенә тикшерү үткәрергә яисә аларның компетенциясе нигезендә әлеге эшчәнлеккә

тикшерү үткәрү турындагы үтенеч белән дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итәргә;

7) ачыкланырга тиешле хәлләргә тикшерү үткәрүдә булышлык күрсәтүне сорап, компетентлы дәүләт органнарына яисә вазыйфаи затларга мөрәҗәгать итәргә;

8) мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча экспертлар тикшерүен һәм бәяләмәләр әзерләүне Татарстан Республикасының компетентлы дәүләт учреждениеләренә һәм фәнни учреждениеләргә йөкләргә;

9) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары утырышларында һәм киңәшмәләрендә катнашырга;

10) үзе куйган мәсьәләләрне карауда һәм тикшерүдә турыдан-туры катнашырга. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ул куйган мәсьәләләрне карау вакыты һәм урыны турында мәсьәлә караласы датага кадәр өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

1) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтергә;

2) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гарызнамәләре буенча аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне, документларны, материалларны, башка мәгълүматны, гарызнамәнең үзендә башка срок билгеләнмәгән булса, гарызнамә алган көннән алып 15 көннән дә соңга калмыйча түләүсез бирергә;

3) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гарызнамәләре буенча бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

4) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча ихтимал һәм кирәкле чараларга кагылышлы тәкъдимнәрен үз эченә алган бәяләмәсен алганнан соң 15 көн эчендә аны карарга һәм күрелгән чаралар турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә язма рәвештә хәбәр итәргә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдимнәре үтәлмәгән очракта, җавапта аларны үтәмәү сәбәпләрен нигезләү булырга тиеш.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә аның карарына йогынты ясау максаты белән тыкшыну, вазыйфаи затларның әлеге Законда билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәве, шулай ук Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә башка рәвешле каршылык күрсәтү законнарда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан рәсми рәвештә таратыла

торган документлар һәм башка мәгълүмати һәм белешмә материаллар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин ителә.

5. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бәйсезлегенең хезмәт өчен түләүгә, медицина, социаль һәм башка тәэмин итүгә һәм хезмәт күрсәтүгә бәйле матди һәм социаль гарантияләре Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

13 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладлары**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил календарь елы тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча үз эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында еллык доклад әзерли.

Әлеге доклад Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

2. Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу турындагы аерым мәсьәләләр буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына махсус докладлар җибәрә ала.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил еллык һәм махсус доклад буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттагы утырышында мәгълүмат белән чыгыш ясарга хокуклы.

4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең еллык һәм махсус докладларын карау нәтиҗәләре буенча әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары җитәкчеләре ачыкланган хокук бозуларны бетерү, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү һәм көчәйтү буенча үз компетенциясе чикләрендә законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

14 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен (шикаятьләрен) карау тәртибе**

1. Мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) караганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил федераль законнардагы һәм "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренә таянып эш итә.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар җитәкчеләренең һәм вазыйфаи затларының бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен боза торган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясе

гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның шикаятьләрен карый.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына шикаять белән балалар, аларның законлы вәкилләре, шулай ук өченче затлар мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Шикаять Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылган көннән яисә мөрәҗәгать итүчегә аларны бозу турында мәгълүм булган көннән алып бер елдан да соңга калмыйча язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә тапшырыла.

5. Әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, шикаятьтә фамилия, исем, атасының исеме, почта адресы һәм, әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресы, карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган органның яисә вазыйфаи затның исеме, мөрәҗәгать итүче фикере буенча бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозган яисә боза торган карарларның яисә гамәлләрнең (гамәл кылмауның) асылы бәян ителеп күрсәтелергә тиеш.

Шикаятькә шикаятьне карау өчен кирәкле документларның һәм башка материалларның күчермәләре кушып бирелә.

Югарыда күрсәтелгән таләпләр турыдан-туры балалар тарафыннан бирелә торган шикаятьләргә кагылмый.

6. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гражданнар арасындагы хокук мөнәсәбәтләренә бәйле бәхәсләр буенча шикаятьләрне карамый.

7. Шикаятьне алганнан соң, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) шикаятьне карауга кабул итәргә;

2) шикаятьне үз компетенциясенә шикаятьне асылда хәл итү керә торган дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка тапшырырга;

3) мөрәҗәгать итүчегә баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өчен ул файдалана ала торган чаралар турында аңлатырга.

8. Шикаятьне карaганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына, аларның вазыйфаи затларына, оешмаларга тикшерү барышында ачыкланырга тиешле теләсә кайсы мәсьәлә буенча үз аңлатмаларын бирү, шулай ук үз позициясен тулаем нигезләү мөмкинлеген бирергә тиеш. Мөрәҗәгать итүче тәкъдим ителгән аңлатмалар белән танышырга мөмкин.

9. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына, аларның вазыйфаи затларына, оешмаларга шикаятьне тапшыра яисә шикаять тикшерүне йөкли алмый.

10. Шикаятьне карaганда алынган материаллар турында соңгы карар чыгарылганга кадәр хәбәр таратылырга тиеш түгел.

11. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында законнарда билгеләнгән вакытларда хәбәр итә.

12. Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу факты ачыкланган очракта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) ул бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозыла дип таныган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органына, аларның вазыйфаи затларына, бозылган хокукларны һәм мәнфәгатьләрне торгызу буенча ихтимал һәм кирәкле чараларга карата тәкъдимнәрне үз эченә алган бәяләмә җибәрергә. Кирәк булган очракта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бәяләмәсе бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуга юл куйган органнарга һәм вазыйфаи затларга караганда югарырак торучы дәүләт хакимияте органнарына һәм вазыйфаи затларга, шулай ук тиешле федераль органнарга җибәрелергә мөмкин;

2) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу чагыла торган вазыйфаи затка карата дисциплинар яисә административ эш йә җинаять эше кузгату турындагы үтенечнамә белән компетентлы дәүләт органнарына мөрәҗәгать итәргә;

3) прокурор йогынтысы чараларын күрү турындагы үтенечнамә белән прокуратура органнарына мөрәҗәгать итәргә.

13. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үзе кабул иткән бәяләмәне бастырып чыгарырга хокуклы. Гамәлгә куючыларының (гамәлгә куюда катнашучыларының) берсе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, дәүләт оешмалары булган йә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслана торган вакытлы матбугат басмасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бәяләмәләрен һәм башка документларын бастырып чыгарудан баш тартырга хокуклы түгел.

## 4 бүлек. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген оештыру һәм финанс ягыннан тәэмин итү**

### 15 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил алдында торучы бурычларны гамәлгә ашыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты (алга таба – аппарат) төзелә.

2. Аппарат юридик зат хокукына ия булган, исәп-хисап һәм башка счетлары булган, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән һәм үз исеме язылган мөһере һәм бланклары булган Татарстан Республикасы дәүләт органыннан гыйбарәт.

3. Аппарат Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген юридик, оештыру, фәнни-аналитик, мәгълүмати-белешмә ягыннан һәм башкача тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

4. Аппарат турындагы нигезләмә, аның структурасы һәм штат расписаниесе Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан раслана.

5. Аппаратка җитәкчелек итүгә һәм үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил боерыклар чыгара.

6. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппарат эшчәнлегенә турыдан-туры җитәкчелек итә, үзенең чыгымнар сметасын мөстәкыйль рәвештә әзерли һәм үти.

7. Аппаратта Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелгән вазыйфаларны биләүче затлар Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре була. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген техник тәэмин итү максатларында аппаратның штат расписаниесенә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән вазыйфалар кертелергә мөмкин.

16 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның аппараты эшчәнлеген финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның аппараты эшчәнлеген финанслауга акчалар ел саен Татарстан Республикасы бюджетында аерым юл белән карала.

3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан финанс хисаплылыгы законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның аппаратының агымдагы эшчәнлеген финанслау аларга үз вәкаләтләрен тулы күләмдә бәйсез рәвештә гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итә.

5. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә һәм аның аппаратына эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәт Татарстан Республикасының дәүләт милке була һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең оператив идарәсендә тора.

17 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил җәмгыяви башлангычларда эшләүче ярдәмчеләр (алга таба – җәмәгать ярдәмчеләре) булдырырга хокуклы.

2. Җәмәгать ярдәмчеләре турындагы нигезләмә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан раслана.

3. Җәмәгать ярдәмчеләренә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан имзаланган тиешле үрнәктәге таныклык бирелә.

18 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы координация һәм киңәшү органнары**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү һәм аңа йөкләнгән бурычларны һәм вәкаләтләрне башкаруның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында координация һәм киңәшү органнары оештырылырга мөмкин.

2. Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү һәм яклау мәсьәләләре буенча консультатив ярдәм күрсәтү, мәсьәләләрне алдан карау һәм тәкъдим итү характерында тиешле тәкъдимнәр әзерләү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә кирәкле белеме булган белгечләрдән торучы экспертлар советы оештырылырга мөмкин.

3. Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү һәм яклау бурычларын хәл иткәндә, кызыксынучы башкарма хакимият органнарының үзара эшчәнлеген һәм килештерелгән гамәлләрен тәэмин итүне оештыру өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында координация комитеты оештырылырга мөмкин.

4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы экспертлар советы һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы координация комитеты составына шулай ук (килешү буенча) дәүләт хакимиятенең башка органнары, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, галимнәр, белгечләр һәм җәмәгать эшлеклеләре кертелергә мөмкин.

5. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы экспертлар советы һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы координация комитеты турындагы нигезләмәләр һәм аларның составлары Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан раслана.

5 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

19 статья. **Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә гамәлдә эш иткән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген гамәлгә ашыру үзенчәлекләре**

"Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә сайланып куелган Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып үзенә билгеләнгән вәкаләтләрне сайланып куелган срогы тәмамланганчыга кадәр гамәлгә ашыра.

20 статья. **"Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

"Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 9 августындагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 5 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) $V^{I}$ бүлеген үз көчен югалткан дип танырга;

3) 36 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү һәм аңа үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы өчен Вәкаләтле вәкил аппараты (алга таба – аппарат) төзелә.";

б) 2 өлештә ", Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 өлештә ", Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил" сүзләрен төшереп калдырырга.

21 статья. **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш), Ватаным Татарстан, 2011, 22 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3 статьяда "Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы Законы" сүзләрен "Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында", "Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы законнары" сүзләренә алмаштырырга;

2) 8.1 статьяның 3 өлешендә:

а) "Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил" сүзләреннән соң "(Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә карата)" сүзләрен өстәргә;

б) "Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил" сүзләреннән соң "(Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә карата)" сүзләрен өстәргә.

22 статья. **"Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы Законына һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.3, 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында**

"Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы Законына һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.3, 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" 2010 елның 28 июнендәге 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктының "в" пунктчасын, 11 пунктын, 12 пунктының "а", "б", "г" пунктчаларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 6 (I өлеш) үз көчләрен югалткан дип танырга.

23 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзләренең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 59-ТРЗ